**СОВЕТ**
**КИЧКЕТАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**КИЧКЕТАҢ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**СОВЕТЫ**

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

13.03.2020 № 61-1

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кичкетаң авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

«Коррупциягә каршы тору турында Россия Федерациясе законнарын камилләштерү максатларында Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 16 декабрендәге 432-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 9 декабрендәге 98-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының "Кичкетаң авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Әгерҗе районы прокуратурасының «Кичкетаң авыл җирлеге Уставының аерым нигезләмәләренә үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 20 гыйнварындагы 02-08-01/45 номерлы протестын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Кичкетаң авыл җирлеге Советы **карар итте**:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кичкетаң авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләрне икенче укылышта кабул итәргә (кушымта итеп бирелә).
2. Әлеге карарны дәүләт теркәвенә алу өчен Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Идарәсенә җибәрергә.
3. Әлеге карарны дәүләт теркәвеннән соң Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Кичкетаң авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Кичкетаң авыл җирлегенең рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында (http://agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка игълан итәргә).

4.Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткерелгәннән) соң үз көченә керә.

5.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Совет Рәисе,
Авыл җирлеге башлыгы З.Р. НУРИЕВ

Татарстан Республикасы
Әгерже муниципаль районы
Кичкетаң авыл җирлеге Советының
13.03.2020 № 61-1
карарына кушымта

**Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районының «Кичкетаң авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр**

**5 статьяның 1 өлешен түбәндәге эчтәлекле 20) пунктын өстәргә:**

«20) Россия Федерациясе граждан законнары нигезендә үз белдеге белән төзелешне сүтү, үз белдеге белән корылган корылманы сүтү яки аны рөхсәт ителгән төзелеш объектларын үзгәртеп кору, җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре белән билгеләнгән капиталь төзелеш объектларының чик параметрларына, территорияне планлаштыру документларына яки федераль законнарда билгеләнгән капиталь төзелеш объектлары параметрларына мәҗбүри таләпләргә туры китерү турында карар кабул итү.»;

**28 статьяның 1 өлешен яңа редакциядә бәян итәргә:**

«1. Җирлек советы бер мандатлы сайлау округлары буенча муниципаль сайлауларда сайланучы җиде депутаттан тора.»;

**29 статьяның 7 өлешен яңа редакциядә бәян итәргә:**

«7. Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатлар хокуклы түгел:

«1) эшмәкәрлек эшчәнлеге белән шәхсән яки ышанычлы затлар аша шөгыльләнергә;

2) коммерция яки коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә катнашу, түбәндәге очраклардан тыш:

а) сәяси партия, һөнәр берлеге органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайлау органы тарафыннан идарә итүдә, башка иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларының, күчемсез милек милек милекчеләр ширкәтенең гомуми җыелышында (конференция) түләүсез катнашу;

б) коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә (сәяси партия, һөнәр берлеге органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайлау органы тарафыннан идарә итүдә, башка иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларының, күчемсез милек милек милекчеләр ширкәтенең гомуми җыелышында (конференция) түләүсез катнашудан тыш), Россия Федерациясе субъекты законында билгеләнгән тәртиптә яллаучы вәкиленең рөхсәте белән түләүсез катнашу;

в) Россия Федерациясе субъектының муниципаль берәмлекләре советында, башка муниципаль берәмлекләрнең берләшмәләрендә, шулай ук аларның идарә органнарында муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә тәкъдим итү;

г) гамәлгә куючысы (акционеры, катнашучысы) муниципаль берәмлек булган идарә органнарында һәм ревизия комиссиясендә, муниципаль берәмлек исеменнән оешманы гамәлгә куючы вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибен билгели торган муниципаль хокукый актлар яки муниципаль милектә булган акцияләр (устав капиталында өлешләр) белән идарә итү тәртибе нигезендә, муниципаль берәмлекне түләүсез нигездә тәкъдим итү;

д) федераль законнарда каралган башка очраклар;».

3) мөгаллимлек, фәнни һәм башка иҗади эшчәнлектән тыш башка түләүле эшчәнлек белән шөгыльләнергә. Шул ук вакытта мөгаллимлек, фәнни һәм башка иҗади эшчәнлек бары тик чит ил дәүләтләре, халыкара һәм чит ил оешмалары, чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар акчалары хисабына гына финанслана алмый, әгәр Россия Федерациясенең халыкара килешүендә яки Россия Федерациясе законнарында башкача каралмаган булса;

4) идарә органнары, попечительләр һәм күзәтчелек советлары, Россия Федерациясе территориясендә эшләүче чит ил коммерцияле булмаган хөкүмәтнеке булмаган һәм аларның структур бүлекчәләре составына керергә, әгәр Россия Федерациясенең халыкара килешүендә яки Россия Федерациясе законнарында башкача каралмаган булса.

7.1. Гражданин контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасына билгеләнә алмый, ә муниципаль хезмәткәр контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын били алмый, әгәр муниципаль берәмлек башлыгы белән якын (яки шундый үзлектәге) туганлыкта (ата-анасы, тормыш иптәше, балалары, абыйлары, сеңелләре, шулай ук тормыш иптәшенең ата-аналары, балалары, абыйлары, сеңелләре һәм балалырының тормыш иптәшләре) торса.».

**41 статьяның 1 өлешендәге 1 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**

«1. Җирлек башлыгы яңа сайланган җирлек советының беренче утырышында җирлек Советы депутатлары арасыннан ачык тавыш бирү юлы белән сайлана, әгәр җирлек Советы тавыш бирүнең башка тәртибен билгеләмәсә, җирлек Советы вәкаләтләре срогына сайлана.»

**48 статьяның 1 өлешендәге 2 пунктына түбәндәге эчтәлекле 10 абзацны өстәргә:**

«- Россия Федерациясе граждан законнары нигезендә үз белдеге белән төзелгән корылманы сүтү, үз белдегең белән корылган корылманы сүтү яки аны рөхсәт ителгән төзелеш, үзгәртеп кору, җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре, территорияне планлаштыру документлары, яисә федераль законнарда билгеләнгән капиталь төзелеш объектлары параметрларына мәҗбүри таләпләр белән тәңгәлләштерү турында карарлар кабул итә.».